**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# «Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Күн авыл җирлеге территориясендә хайваннар котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында

Хайваннарның котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм:**

1. Әлеге Указның 2 пункты нигезендә билгеләнгән эпизоотия чыганагы һәм имин булмаган пункт территорияләрендә хайваннар котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертергә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

а) эпизоотия чыганагын – «Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Күн авыл җирлегенең төньяк киңлекнең 55,6749 градусы һәм көнчыгыш озынлыкның 49,7566 градусы географик координатларыннан 300 метр радиуста урнашкан территориясе;

б) имин булмаган пунктны – «Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Күн авыл җирлеге территориясе.

3. Түбәндәгеләрне тыярга:

а) эпизоотия чыганагында:

котыру чиренә бирешүчән авыру хайваннарны дәвалауны;

җитештерү белән бәйле (технологик) операцияләрне, шул исәптән котыру чиренә бирешүчән хайваннарга хезмәт күрсәтүче персоналдан, эпизоотия чыганагын бетерүдә катнашучы дәүләт ветеринария хезмәте белгечләре һәм персоналдан, эпизоотия чыганагы территориясендә яшәүче һәм (яисә) вакытлыча торучы затлардан кала территориягә чит кешеләр керүен;

котыру чиренә бирешүчән хайваннар үләксәләренең тиреләрен салдыруны;

аучылык ресурсларының санын җайга салу максатларында аулаудан тыш, аучылык ресурсларына кертелгән котыру чиренә бирешүчән хайваннарны аулау;

б) имин булмаган пунктта:

ярминкәләр, күргәзмәләр (сату итү) уздыру һәм котыру чиренә бирешүчән хайваннарны күчереп йөртү һәм туплау белән бәйле башка чаралар үткәрүне;

котыру чиренә бирешүчән хайваннарны читкә чыгаруны;

котыру чиренә бирешүчән кыргый хайваннарны зоопаркларга чыгару өчен аулауны.

4. Карантин котыру чире белән авырый дигән шик тудыра торган котыру чиренә бирешүчән соңгы хайван суелган һәм (яисә) котыру чиренә бирешүчән соңгы авыру хайванның үләксәсе юкка чыгарылган көннән 60 календарь көн узгач, башка тиешле чаралар үтәлгәч бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 2 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә хайваннарның котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга, шулай ук аның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

6. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

7. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын башкаручы** **А.В. Песошин**

Казан, Кремль
2021 ел, 05 август
№ ПУ-630